КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 июнь г.Казань № 382

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы; 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче; 2011 ел, 28 апрель, 347 нче; 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы; 2011 ел, 25 июль, 576 нчы; 2011 ел, 19 август, 688 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нче; 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче; 2012 ел, 25 апрель, 323 нче; 2012 ел, 1 июнь, 464 нче; 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 457 нче; 2013 ел, 26 август, 600 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче; 2015 ел, 20 февраль, 104 нче; 2015 ел, 10 март, 140 нчы; 2015 ел, 8 апрель, 230 нчы; 2015 ел, 16 май, 350 нче; 2015 ел, 14 август, 591 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 889 нчы; 2015 ел, 30 декабрь, 1031 нче; 2016 ел, 26 гыйнвар, 38 нче; 2016 ел, 13 май, 314 нче; 2016 ел, 20 июль, 491 нче; 2016 ел, 30 сентябрь, 698 нче; 2017 ел, 16 март, 146 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

8 бүлекнең 6 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 таблица

| Структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри-квалификация төркеменең квалификация дәрәҗәләре | Оешма җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Өстәмә түләү күләме, зурлыгы, процент |
|---|---|---|
| 1 | - | 4,5 (39,5*) |
| 2 | - | 7,5 (42,5*) |
| 3 | 1 | 87,0 |
| | 2 | 87,0 |
| | 3 | 68,5 |
| | 4 | 61,0 |
| | төркемнән тыш | 52,0 |
| *Өстәмә белем бирү оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре өчен.»; | | |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлекнең 2.4 пунктындагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$K_{mj}$ – физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларының физик культура һәм спорт педагогика хезмәткәрләре һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирүче оешмаларның спорт буенча тренер-укытучылары өчен тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты 1,565 тәшкил итә;».

2. Бу карарның көче 2017 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\382.docx